СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

« 09 » сентябрь 2020 ел № 348

**Арча район Советының 2018 елның 24 апрелендәге 168 номерлы «Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләрнең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәре һәм шартлары турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында кодексы, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләүләре күләмен арттыру турында" карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2018 елның 24 апрелендәге 168 номерлы «Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәре һәм шартлары турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларның хезмәтләре өчен түләү турындагы Нигезләмәнең 2 абзацын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәте өчен түләү акчалата түләү формасында башкарыла.

| Вазыйфа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Арча муниципаль районы башлыгы | 30442 |

| | |
|---|---|
| Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары | 27398 |
| Арча муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе | 27398 |

2) Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль учреждениеләрдә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәтләренә түләү турындагы Нигезләмәнең 16 абзацында (2 нче кушымта) «11 163 сум» сүзләрен «11 498 сум» сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәнең 10 абзацында (3 нче кушымта) «11 163 сум» сүзләрен «11 498 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 1.10.2020 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев